# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Кадыбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Кадыбаш торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**от 30.11.2021** **№ 1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Кадыбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Кадыбаш торак пунктында гражданнарның үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча 2021 елның 30 ноябрендә 13 сәгать 00 минутта, 2021 елның 30 ноябрендә 14 сәгать 30 минутта этаплап уздырылган гражданнар җыены нәтиҗәләре турында түбәндәге сорау буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

«2022 елда Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Кадыбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Кадыбаш торак пункты территориясендә, I төркем инвалидлардан, көндезге формада белем алучы студентлардан, иректән мәхрүм итү урыннарындагы затлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәм балигъ булган һәр кешедән 500 сум күләмендә үзара салым акчалары җыюны кертүгә һәм алардан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен файдалануга ризамы:

1) Кадыбаш авылында скважиналар өчен тирәнлек насослары сатып алу һәм ремонтлау, су үткәрү челтәрен ремонтлау;

2)Кадыбаш авылында урамнарны яктырту чаралары (урам яктырткычларын,электр товарларын сатып алу, урнаштыру, алмаштыру һәм хезмәт шартнамәсе буенча электрикка түләү);

3)Кадыбаш авылында урамнарны кардан чистарту (юлларга хезмәт күрсәтү,үләннәрне чабу, дизель ягулыгы сатып алу, кардан чистарту, Кадыбаш авылында тракторга дизель мае алу, хезмәт килешүе буенча тракторчыга түләү);

4)Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (янгын сүндерү машинасын карап тоту һәм хезмәт шартнамәсе буенча янгын сүндерү машинасы йөртүчесенә түләү, янгын сүндерү машинасына бензин сатып алу, запас частьлар сатып алу);

5) Кадыбаш авылында Гали урамына бара торган юл өслеге өчен ком һәм вак таш сатып алу, төяү, каплау, юл салу;

6) Кадыбаш авылы территориясендә хуҗасыз йортларның фасадларын алыштыру (төзелеш материаллары сатып алу һәм башкарылган эшләр өчен хезмәт килешеүе буенча түләү);

7) МТЗ тракторы өчен асылма җиһазлар сатып алу.

8) 3 штук бензочапкыч, 2 штук бензопычкы, бензин һәм май сатып алу,агачлар кисү,үләннәрне чабу.

«РИЗА» «КАРШЫ».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 275 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны - 144 кеше, бу 52,4 % тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"РИЗА" позициясе өчен гражданнар җыенында 144 катнашучы тавыш бирде; "КАРШЫ" позициясе өчен җыенда 0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Кадыбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Кадыбаш торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләре - дөрес дип танырга.

2. 2022 елда Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Кадыбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Кадыбаш торак пункты территориясендә, I төркем инвалидлардан, көндезге формада белем алучы студентлардан, иректән мәхрүм итү урыннарындагы затлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәм балигъ булган һәр кешедән 500 сум күләмендә үзара салым акчалары җыюны кертергә.

3. Җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә:

1) Кадыбаш авылында скважиналар өчен тирәнлек насослары сатып алу һәм ремонтлау, су үткәрү челтәрен ремонтлау;

2) Кадыбаш авылында урамнарны яктырту чаралары (урам яктырткычларын, электр товарларын сатып алу, урнаштыру, алыштыру һәм хезмәт шартнамәсе буенча электрикка түләү);

3) Кадыбаш авылында урамнарны кардан чистарту (юлларга хезмәт күрсәтү, кардан чистарту, ягулык-майлау материаллары - дизель ягулыгы, трактор өчен дизель мае сатып алу, тракторчыга хезмәт килешүе буенча түләү);

4)Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (янгын сүндерү машинасы өчен ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу һәм янгын сүндерү машинасының машина йөртүчесенә хезмәт килешүе буенча түләү);

5) Кадыбаш авылында Гали урамына бара торган юл өслеге өчен ком һәм вак таш сатып алу, төяү, каплау, юл салу, ягулык-майлау материаллары сатып алу;

6) МТЗ тракторына асылмалы җиһазлар сатып алу, үлән чабу, ягулык-майлау материаллары сатып алу;

7) Кадыбаш авылы территориясендә хуҗасыз йортларның фасадларын алыштыру (төзелеш материаллары сатып алу һәм башкарылган эшләр өчен хезмәт килешүе буенча түләү);

8) Чүп һәм корыган куакларны чабу өчен бензин чапкычы, бензопычкы сатып алу;

9) Җирләү урыннарын карап тоту (иске, корыган агачларны кисү).

- Тыл хезмәтчәннәре өчен мемориаль такта әзерләү һәм урнаштыру;

4. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендында элеп халыкка җиткерергә, “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (https://www.agryz.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
авыл җирлеге Башлыгы Х.Л.ЗАКИРОВ